| | |
|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ<br>РАЙОННЫЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>8 ноября 2021 г. | **КАРАР**<br>№ 85 |

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турында Нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү, идарә структурасын камилләштерү максатларында, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Район Советының 2021 елның 19 февралендәге 44 номерлы карары белән (2011 елның 27 декабрендәге 73 номерлы, 2012 елның 6 июнендәге 113 номерлы, 2014 елның 27 маендагы 228 номерлы үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турында Нигезләмәне үз көчен югалткан дип танырга.

3. Балтач муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе Сабиров Ирек Сәяф улына, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 10 нчы районара салым инспекциясендә Татарстан Республикасы Контроль-хисап палатасы Нигезләмәсен һәм Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында башка үзгәрешләрне теркәгәндә мөрәҗәгать итүче булырга, бу максатларда кирәкле гаризаларны һәм башка документларны имзаларга, законнарда каралган тәртиптә һәм вакытларда башка гамәлләр кылырга һәм формальлекләрне үтәргә вәкаләт бирергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.Н.Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин

Балтач район Советының
2021 елның «08» ноябренең
85 номерлы карарына
кушымта

# Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турында Нигезләмә

**1 статья. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Контроль-хисап палатасы статусы**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Контроль-хисап палатасы (алга таба – Контроль-хисап палатасы) тышкы муниципаль финанс контрольнең даими эшләүче органы булып тора, Балтач район Советы тарафыннан төзелә һәм аңа хисап тота.

2. Контроль-хисап палатасы оештыру һәм функциональ бәйсезлеккә ия һәм үз эшчәнлеген мөстәкыйль гамәлгә ашыра.

3. Контроль-хисап палатасының эшчәнлеге, шул исәптән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу сәбәпле, туктатыла алмый.

4. Контроль-хисап палатасы җирле үзидарә органы булып тора, аның герблы мөһере һәм үз исеме һәм муниципаль берәмлек гербы сурәтләнгән бланклары бар.

5. Контроль-хисап палатасы юридик зат хокукларына ия[1].

6. Контроль-хисап палатасы үз эшчәнлеге һәм тышкы муниципаль финанс контроле вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча хокукый инициативага ия.

7. Контроль-хисап палатасы ведомство бүлекләрен һәм аерымлык билгеләрен гамәлгә куя, әлеге бүлекләр һәм билгеләр турында нигезләмәләрне, аларның тасвирламаларын һәм рәсемнәрен, бүләкләү тәртибен раслый ала.

8. Контроль-хисап палатасы Балтач муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан мондый вәкаләтләрне тапшыру турында Балтач район Советы белән килешү төзелгән очракта, тышкы финанс контролен гамәлгә ашыру буенча җирлекнең контроль-хисап органы вәкаләтләрен башкара[2].

9. Контроль-хисап палатасының урнашу урыны:

Юридик адрес: 422250, Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Балтач штп., Ленин урамы, 42 нче йорт.

Факттагы адрес: 422250, Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Балтач штп., Ленин урамы, 42 нче йорт.

---

[1] Әлеге пункт муниципаль район, муниципаль округ, шәһәр округы, шәһәр эчендәге бүленеш белән шәһәр округы статусы бирелгән муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органнарына, шулай ук муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән юридик зат хокуклары бирелгән очракта, башка муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарына карата кулланыла.

[2] Әлеге пункт муниципаль районның КХП турында нигезләмәләргә генә кертелә.

**2 статья. Контроль-хисап палатасы эшчәнлегенең хокукый нигезләре**

Контроль-хисап палатасы үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Балтач муниципаль районы Уставы, әлеге Нигезләмә һәм башка муниципаль хокукый актлар нигезендә башкара.

**3 статья. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге принциплары**

Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге законлылык, объективлык, нәтиҗәлелек, бәйсезлек, ачыклык һәм хәбәрдарлык принципларына нигезләнә.

**4 статья. Контроль-хисап палатасы составы**

1. Контроль-хисап палатасы Контроль-хисап палатасы рәисеннән һәм аппараттан тора.
2. Контроль-хисап палатасы рәисе муниципаль вазыйфаны били.
3. Контроль-хисап палатасы рәисе вәкаләтләре вакыты 5 ел тәшкил итә[3].
4. Контроль-хисап палатасы аппараты составына башка штат хезмәткәрләре дә керә. Контроль-хисап палатасы инспекторларына тышкы муниципаль финанс контролен оештыру һәм үткәрү буенча бурычлар йөкләнә.
5. Контроль-хисап органы хезмәткәрләренең хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында законнар, хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар белән билгеләнә.
6. Контроль-хисап палатасының штат саны, законнар белән йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү, оештыру һәм функциональ бәйсезлекне тәэмин итү зарурлыгын исәпкә алып, Контроль-хисап палатасы рәисе күрсәтмәсе буенча Балтач район Советының хокукый акты белән билгеләнә.
7. Контроль-хисап палатасының структурасы һәм штат расписаниесе[4], Контроль-хисап палатасына йөкләнгән вәкаләтләрдән чыгып, Контроль-хисап палатасы рәисе тарафыннан раслана.

**5 статья. Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына билгеләү һәм вазыйфадан азат итү тәртибе**

1. Контроль-хисап палатасы рәисен вазыйфага Балтач район Советы билгеләнә.
2. Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәр Балтач район Советына түбәндәгеләрдән кертелә:

1) Балтач район Советы рәисе (Балтач муниципаль районы башлыгы);

2) Балтач район Советы депутатлары - Балтач район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән бере.

3. Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына кандидатуралар Балтач район Советына әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән субъектлар тарафыннан контроль- хисап палатасының гамәлдәге рәисе вәкаләтләре беткәнче ике айдан да соңга ________________

[3] Контроль-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторларының вәкаләтләре вакыты муниципаль норматив хокукый акт белән билгеләнә һәм вәкиллекле орган вәкаләтләре вакытыннан ким булмаска тиеш.

[4] Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән контроль-хисап органы структурасын билгеләүнең башка тәртибе каралмаган булса.

калмыйча тапшырыла[5].

5. Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына кандидатураларны карау тәртибе Балтач район Советы регламенты белән билгеләнә.

**6 статья. Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына кандидатураларга таләпләр**

1. Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына түбәндәге квалификация таләпләренә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнары билгеләнә:

1) югары белем булу;

2) дәүләт, муниципаль идарә, дәүләт, муниципаль контроль (аудит), икътисад, финанс, юриспруденция өлкәсендә биш елдан да ким булмаган эш тәҗрибәсе;

3) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль законнарны, шул исәптән Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актларны, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы конституциясен, законнарын һәм башка норматив хокукый актларны, Балтач муниципаль районы Уставын һәм вазыйфаи бурычларны үтәүгә карата башка муниципаль хокукый актларны, шулай ук Россия Федерациясе Хисап палатасы тарафыннан расланган Татарстан Республикасы һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль һәм эксперт-аналитик чараларын үткәрү өчен тышкы дәүләт һәм муниципаль аудит (контроль) стандартларына карата гомуми таләпләрне белү.

2. Россия Федерациясе гражданы түбәндәге очракларда Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына билгеләнә алмый:

1) хөкем ителгәнлеге бетерелмәгән яисә суд хөкемен тулысынча үтәп бетермәгән булу;

2) законлы көченә кергән суд карары белән хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип танылу;

3) әгәр дә граждан биләүгә дәгъва кылучы вазыйфа буенча бурычларны үтәү мондый белешмәләрне файдалануга бәйле булганда, дәүләт һәм федераль

закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләргә рөхсәт рәсмиләштерү процедурасын узудан баш тарту;

4) Россия Федерациясе гражданлыгы тукталу яисә чит ил гражданлыгы (башка илгә буйсынганлыгы) яисә яшәүгә рөхсәте булу яки чит ил дәүләте территориясендә Россия Федерациясе гражданының даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булу;

5) әлеге статьяның 3 пунктында каралган нигезләрнең булуы.

3. Контроль-хисап палатасы рәисе Балтач муниципаль районы башлыгы, Балтач район Советы рәисе, Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе[6], Балтач

[5] Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән башка тәртип билгеләнмәгән очракта. [6] Җирле администрация башлыгы муниципаль берәмлек башлыгы булмаса, күрсәтелә.

муниципаль районы территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлыкта яки кардәшлектә (ата-аналар, ир белән хатын, балалар, абыйлары-энеләре, апалары-сеңелләре, шулай ук ирнең (хатынның) абыйлары-энеләре, апалары-сеңелләре, әти-әнисе, балалары һәм балаларның ирләре (хатыннары)) була алмый.

4. Контроль-хисап палатасы рәисе, укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнә алмый. Шул ук вакытта укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яки Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар хисабына гына финанслана алмый.

5. Контроль-хисап палатасы рәисе Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырырга тиеш.

**7 статья. Контроль-хисап палатасы вазыйфаи затларының статусы гарантияләре**

1. Контроль-хисап палатасы рәисе һәм инспекторлары контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары булып торалар.

2. Вазыйфаи вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга комачаулау яки алар тарафыннан кабул ителгән карарларга йогынты ясау максатларында Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларына нинди дә булса формада йогынты ясау, шулай ук Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларына карата көчләү, мәсхәрәләү, яла ягу яисә аларның эшчәнлеге турында белә торып ялган мәгълүмат тарату Россия Федерациясе законнарында һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән җаваплылыкка тартуга китерә.

3. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары судьяларны, хокук саклау һәм контрольдә тоту органнарының вазыйфаи затларын дәүләт яклавы турында Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт тарафыннан яклана.

4. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары һөнәри бәйсезлек гарантияләренә ия.

5. Контроль-хисап палатасы рәисе түбәндәге нигезләр буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә вакытыннан алда вазыйфасыннан азат ителә:

1) рәискә карата судның гаепләү карарының законлы көченә керүе;

2) аларны законлы көченә кергән суд карары белән хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикләнгән дип тану;

3) Россия Федерациясе гражданлыгы тукталу яисә чит ил гражданлыгы (башка илгә буйсынганлыгы) яисә яшәүгә рөхсәте булу яки чит ил дәүләте территориясендә Россия Федерациясе гражданының даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булу;

4) отставкага китү турында язмача гариза бирелү;

5) үзенә йөкләнгән вазыйфаи вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозу яисә вазыйфаи вәкаләтләрдән явызларча файдалану, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелеге аны вакытыннан алда азат итү турында карар өчен тавыш бирсә;

6) федераль закон нигезендә Балтач район Советының норматив хокукый актында билгеләнгән вазыйфада булуның иң чик яшенә җитү;

7) әлеге Нигезләмәнең 6 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә каралган хәлләр ачыклану;

8) "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрорльдә тоту турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, "Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларны саклауны, саф акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү.

**8 статья. Контроль-хисап палатасы вәкаләтләре**

1. Контроль-хисап палатасы түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

1) җирле бюджет акчаларын, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда башка акчаларны куллануның законлылыгын һәм

нәтиҗәлелеген контрольдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) җирле бюджет проектларына экспертиза үткәрү, аның күрсәткечләренең нигезле булуын тикшерү һәм анализлау;

3) җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү;

4) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә аудит үткәрү;

5) муниципаль милек формалаштыру, мондый милек белән идарә итү һәм аның белән эш итү нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мондый милек формалаштыру, мондый милек белән идарә итү һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне контрольдә тоту (интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукларны да кертеп);

6) җирле бюджет акчалары исәбеннән салым һәм башка ташламалар һәм өстенлекләр, бюджет кредитлары бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук муниципаль гарантияләр һәм йөкләмәләр бирүнең яисә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан җирле бюджет һәм муниципаль милектәге мөлкәт акчалары исәбеннән башкарыла торган алыш-бирешләр буенча башка ысуллар белән йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итүнең законлылыгын бәяләү;

7) Балтач муниципаль районының чыгым йөкләмәләренә кагылышлы өлешендә муниципаль хокукый актлар проектларына экспертиза, җирле бюджет керемнәрен үзгәртүгә китерә торган муниципаль хокукый актлар проектларына, шулай ук муниципаль программаларга (муниципаль программалар проектларына) экспертиза үткәрү;

8) муниципаль берәмлектә бюджет процессын анализлау һәм мониторинглау, шул исәптән бюджет процессында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм Россия Федерациясе бюджет законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

9) агымдагы финанс елында җирле бюджетның үтәлешенә оператив анализ ясау һәм аның үтәлешен контрольдә тоту, җирле бюджет үтәлешенең барышы, үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитика чаралары нәтиҗәләре турында квартал саен Балтач район Советына һәм Балтач муниципаль районы башлыгына мәгълүмат тапшыру;

10) муниципаль эчке һәм тышкы бурыч торышына контрольне гамәлгә ашыру;

11) Контроль-хисап палатасы компетенциясе кысаларында муниципаль берәмлекне стратегик планлаштыру документларында каралган муниципаль берәмлекне социаль-икътисадый үстерү максатларына ирешү гамәлгә ашырылуын, куркынычын һәм нәтиҗәләрен бәяләү;

12) вәкаләтләр чикләрендә коррупциягә каршы торуга юнәлдерелгән

чараларда катнашу;

13) тышкы муниципаль финанс контроле өлкәсендә федераль законнарда, Россия Федерациясе субъекты законнарында, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы уставында һәм норматив хокукый актларында билгеләнгән башка вәкаләтләр.

2. Тышкы дәүләт һәм муниципаль финанс контроле Контроль-хисап палатасы тарафыннан түбәндәгеләргә карата башкарыла:

1) муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль органнарга, муниципаль учреждениеләргә һәм муниципаль берәмлекнең унитар предприятиеләренә, шулай ук муниципаль берәмлекнең муниципаль милкендәге мөлкәтне кулланcалар, башка оешмаларга карата;

2) Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм башка федераль законнарда каралган башка затларга карата.

**9 статья. Тышкы муниципаль финанс контролен тормышка ашыру формалары**

1. Тышкы муниципаль финанс контроле Контроль-хисап палатасы тарафыннан контроль яки экспертиза-аналитик чаралар рәвешендә башкарыла.

2. Контроль чаралар үткәргәндә Контроль-хисап палатасы тарафыннан тикшерелә торган органнар һәм оешмалар җитәкчеләренә җиткерелә торган тиешле акт (актлар) төзелә. Акт (актлар) нигезендә Контроль-хисап палатасы тарафыннан хисап төзелә.

3. Эксперт-аналитик чара үткәргәндә Контроль-хисап палатасы тарафыннан хисап яки бәяләмә төзелә.

**10 статья. Тышкы муниципаль финанс контроле стандартлары**

1. Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашырганда Контроль-хисап палатасы Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларына, шулай ук тышкы муниципаль финанс контроле стандартларына таяна.

2. Контроль һәм эксперт-аналитик чаралар үткәрү өчен тышкы муниципаль финанс контроле стандартлары Россия Федерациясе Хисап палатасы тарафыннан расланган гомуми таләпләр нигезендә Контроль-хисап палатасы тарафыннан раслана.

3. Тышкы муниципаль финанс контроле стандартларын әзерләгәндә дәүләт контроле, аудит һәм финанс хисабы өлкәсендә халыкара стандартлар исәпкә алына.

4. Контроль-хисап палатасы тарафыннан расланган тышкы муниципаль финанс контроле стандартлары Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килә алмый.

**11 статья. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеген планлаштыру**

1. Контроль-хисап палатасы үз эшчәнлеген мөстәкыйль эшләнә һәм раслана торган планнар нигезендә башкара.

2. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеген планлаштыру контроль һәм экспертиза-аналитик чаралар нәтиҗәләрен исәпкә алып, шулай ук муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы йөкләмәләре, муниципаль берәмлек башлыгы тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Контроль-хисап палатасының киләсе елга эш планы органның Контроль-хисап палатасы рәисе тарафыннан 30 декабрьгә кадәр раслана.

3. Контроль-хисап палатасына план төзелә торган елга кадәр килүче елның 15 декабренә кадәр җибәрелгән Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары белән кабул ителгән йөкләмәләр, Балтач муниципаль районы башлыгының тәкъдимнәре Контроль-хисап палатасының киләсе елга эш планына мәҗбүри кертелергә тиеш.

4. Контроль-хисап палатасының эш планына кертү өчен ел дәвамында килгән Контроль-хисап палатасының эш планына үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы Балтач район Советы йөкләмәсе, Балтач муниципаль районы башлыгы тәкъдимнәре Контроль-хисап палатасы коллегиясенең якын тирәдәге утырышында карала.

**12 статья. Контроль-хисап палатасы регламенты**

1. Контроль-хисап палатасы регламенты түбәндәгеләрне билгели:

- Контроль-хисап палатасы эшчәнлегенең юнәлешләрен карап тотуны;

- контроль һәм эксперт-аналитика чараларын әзерләү һәм үткәрү мәсьәләләрен;

- эш башкаруны алып бару тәртибен;

- контроль һәм экспертиза-аналитик чаралар үткәрү өчен кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны бирү турында гарызнамәләр җибәрү тәртибен;

- Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару яки Интернет челтәрендә урнаштыру процедурасын;

- Контроль-хисап палатасының эчке эшчәнлегенең башка мәсьәләләрен.

2. Контроль-хисап палатасы регламенты Контроль-хисап палатасы рәисе тарафыннан раслана.

**13 статья. Контроль-хисап палатасы вазыйфаи затларының таләпләрен үтәү мәҗбүрилеге**

1. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларының Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль берәмлекнең

норматив хокукый актларында билгеләнгән үз вазыйфаи вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле таләпләре һәм гарызнамәләре җирле үзидарә органнары һәм муниципаль органнар, тышкы муниципаль финанс контроле гамәлгә ашырыла торган оешмалар (алга таба - тикшерелә торган органнар һәм оешмалар) тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри булып тора.

2. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларының законлы таләпләрен һәм гарызнамәләрен үтәмәү, шулай ук аларга йөкләнгән вазыйфаи вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга комачаулау Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән җаваплылыкка тартуга китерә.

**14 статья. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеген оештыру буенча рәис вәкаләтләре**

1.Контроль-хисап палатасы рәисе:

1) Контроль-хисап палатасы эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

2) Контроль-хисап палатасы регламентын раслый;

3) Контроль-хисап палатасының эш планнарын һәм аларга үзгәрешләрне раслый;

4) Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге турында еллык хисапны раслый;

5) тышкы муниципаль финанс контроле стандартларын раслый;

6) Контроль-хисап палатасының контроль һәм экспертиза-аналитик чаралар нәтиҗәләрен раслый; Контроль-хисап палатасы күрсәтмәләренә һәм представлениеләренә имза куя;

7) Татарстан Республикасы Балтач район Советына һәм Балтач муниципаль районы башлыгына Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге турында еллык отчет, үткәрелгән контроль һәм экспертиза-аналитик чаралар нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирә;

8) Россия Федерациясе дәүләт органнарында, Татарстан Республикасы Дәүләт органнарында һәм җирле үзидарә органнарында Контроль-хисап палатасы исеменнән эш итә;

9) Контроль-хисап палатасының структурасын һәм штат расписаниесен, структур бүлекчәләр турында нигезләмәләрне һәм Контроль-хисап палатасы хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләрен раслый;

10) Контроль-хисап палатасы аппараты хезмәткәрләрен яллаучы вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

11) Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары өчен билгеләнгән гарантияләрне гамәлгә ашыру турында хокукый актлар раслый;

12) Контроль-хисап палатасы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар (боерыклар, күрсәтмәләр) чыгара.

**15 статья. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларының хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы**

1. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары үзләренә йөкләнгән вазыйфаи вәкаләтләрне башкарганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерелә торган органнар һәм оешмалар тарафыннан биләнә торган территориягә һәм биналарга тоткарлыксыз керергә, аларның документларыннан һәм материалларыннан файдаланырга, шулай ук алар биләгән территорияләрне һәм бүлмәләрне карарга;

2) подделкалар, ялган документлар ясау, урлаулар, явызларча файдаланулар ачыкланганда һәм әлеге хокукка каршы гамәлләрне булдырмау очрагында кассаларны, касса һәм хезмәт урыннарын, тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның складларын һәм архивларын мөһерләп ябып куярга, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне исәпкә алып, документларны һәм материалларны тартып алырга. Кассаларны, касса һәм хезмәт урыннарын, складларны һәм архивларны мөһерләп ябып кую, документларны һәм материалларны тартып алу тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның вәкаләтле вазыйфаи затлары катнашында һәм тиешле актлар төзү белән башкарыла;

3) үз компетенциясе кысаларында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнарының, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарының һәм дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль органнарның, оешмаларның вазыйфаи затларына гарызнамәләр җибәрергә;

4) үз компетенциясе кысаларында тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның җитәкчеләреннән һәм башка вазыйфаи затларыннан тикшерү чараларын үткәргәндә ачыкланган бозу фактлары буенча язмача аңлатмалар, шулай ук кирәкле документларның билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәләрен бирүне таләп итәргә;

5) тикшерү чараларын үткәргәндә, тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның вазыйфаи затлары тарафыннан соралган документларны һәм материалларны тапшырмау яисә вакытында тапшырмау фактлары буенча актлар төзергә;

6) үз компетенциясе кысаларында тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлегенә кагылышлы барлык кирәкле документлар белән, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә дәүләт, хезмәт, коммерция һәм закон белән саклана торган башка серләрне үз эченә алган документлар белән танышырга;

7) тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлегенә кагылышлы һәм тикшерелә торган органнарның һәм

оешмаларның мәгълүмат базаларында электрон формада саклана торган мәгълүмат белән, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә дәүләт, хезмәт, коммерция һәм закон тарафыннан саклана торган башка серне үз эченә алган мәгълүмат белән танышырга;

8) мәгълүматларның электрон базаларына техник документлар белән танышырга;

9) әгәр мондый хокук Россия Федерациясе законнарында, Россия Федерациясе субъекты законнарында каралган булса, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында каралган очракта, кассалар, касса һәм хезмәт урыннары, складлар һәм архивлар мөһерләп ябып куелса, документларны һәм материалларны тартып алынса, Контроль-хисап палатасы вазыйфаи затлары кичекмәстән (24 сәгать эчендә) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Контроль-хисап органы рәисенә хәбәр итәргә тиеш.

3. Контроль-хисап палатасы вазыйфаи затларының тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның оператив-хуҗалык эшчәнлегенә тыкшынырга, шулай ук контроль чаралар үткәргәндә алынган мәгълүматны таратырга, контроль чаралары тәмамланганчы һәм тиешле актлар һәм хисаплар төзелгәнче үз нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә хокукы юк.

4. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары тикшерелә торган органнарда һәм оешмаларда контроль һәм эксперт-аналитик чаралар үткәргәндә билгеле булган дәүләт, хезмәт, коммерция һәм закон белән саклана торган башка серләрне сакларга, аларның нәтиҗәләрен Контроль-хисап палатасының тиешле актларында, хисапларында һәм бәяләмәләрендә объектив һәм дөрес чагылдырырга тиеш.

5. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларны саклауны, саф акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш.

6. Контроль-хисап палатасы вазыйфаи затлары алар үткәрә торган контроль һәм эксперт-аналитик чаралар нәтиҗәләренең дөреслеге һәм объективлыгы өчен, шулай ук дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка серләрне игълан иткән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.

7. Контроль-хисап палатасы рәисе яки ул вәкаләтләр биргән Контроль-хисап палатасы хезмәткәрләре Балтач район Советы, аның комитетлары, комиссияләре һәм эш төркемнәре утырышларында, Балтач муниципаль районы башлыгы, Балтач район башкарма комитеты, Балтач муниципаль районы башлыгы каршындагы координация һәм киңәшләшү органнары киңәшмәләрендә катнашырга хокуклы.

**16 статья. Контроль-хисап палатасына мәгълүмат бирү**

1. Аларга карата контроль-хисап органы тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашырырга хокуклы яисә тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматка ия, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән органнар, оешмалар һәм аларның вазыйфаи затлары контроль-хисап органы гарызнамәләре буенча гарызнамәдә күрсәтелгән яисә Россия Федерациясе субъектлары законнары белән билгеләнгән вакытта контроль һәм эксперт-аналитик чаралар үткәрү өчен кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны тапшыра.

2. Контроль-хисап органнары тарафыннан әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гарызнамәләрне җибәрү тәртибе муниципаль хокукый актлар һәм Контроль-хисап органы Регламенты белән билгеләнә.

3. Контроль-хисап палатасы тарафыннан тышкы муниципаль финанс контролен чараларын гамәлгә ашырганда тикшерелә торган органнар һәм оешмалар Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларына идарә итү һәм башка хисап һәм документлар белән, муниципаль берәмлек бюджетын формалаштыру һәм үтәү, муниципаль милекне куллану белән бәйле документлар белән, тикшерелә торган органнар һәм оешмалар тарафыннан кулланыла торган муниципаль мәгълүмат системалары һәм аларга техник документлар белән танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Тикшерелә торган органнар һәм оешмалар җитәкчеләре Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затлары эше өчен кирәкле шартлар тудырырга, контроль чараларда катнашучы Контроль-хисап палатасының әлеге вазыйфаи затларын белешмә хокукый системаларга, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә керү мөмкинлеге булган җиһазландырылган эш урыны белән тәэмин итәргә бурычлы.

4. Балтач район башкарма комитеты Контроль-хисап палатасына бюджет хисаплылыгын, финанс хисаплылыгын, муниципаль берәмлек бюджетының расланган җыелма бюджет язмасын муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта җибәрә.

5. Контроль-хисап палатасына аның гарызнамәсе буенча контроль һәм эксперт-аналитик чараларны үткәрү өчен кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны тапшырмау яки вакытында тапшырмау,

шулай ук мәгълүматны, документларны һәм материалларны тулы күләмдә тапшырмау яки дөрес булмаган мәгълүмат, документлар һәм материаллар тапшыру Россия Федерациясе законнарында һәм (яки) Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән җаваплылыкка тартуга китерә.

6. Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашырганда Контроль-хисап палатасына мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында Россия Федерациясе законнары, дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары нигезендә аның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларыннан даими файдалану мөмкинлеге бирелә.

**17 статья. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәләре (представлениеләре) һәм күрсәтмәләре (предписаниеләре)**

1. Контроль-хисап палатасы контроль чаралар үткәрү нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль органнарга, тикшерелә торган органнарга һәм оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына ачыкланган бюджет һәм башка бозуларны, җитешсезлекләрне бетерү, муниципаль берәмлеккә матди зыян китерүне булдырмау яки китерелгән зыянны каплау, хокук бозуларда гаепле вазыйфаи затларны җаваплылыкка тарту, шулай ук бозуларны туктату, бетерү һәм кисәтү буенча чаралар күрү өчен күрсәтмәләр (представлениеләр) кертергә хокуклы.

2. Контроль-хисап палатасы представлениесенә Контроль-хисап палатасы рәисе имза куя.

3. Җирле үзидарә органнары, муниципаль органнар, башка оешмалар күрсәтмәләрендә (представлениедә) күрсәтелгән вакытта яисә, әгәр вакыты күрсәтелмәгән булса, аны алганнан соң 30 көн эчендә бирелгән күрсәтмәләрне (представлениене) үтәү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлар һәм чаралар турында Контроль-хисап органына язмача хәбәр итәргә тиеш.

4. Күрсәтмәләрне (представлениеләрне) үтәү вакыты Контроль-хисап палатасы карары буенча озайтылырга мөмкин, ләкин бер тапкырдан да артык түгел.

5. Аларны туктату һәм кисәтү буенча кичектергесез чаралар күрүне таләп итә торган закон бозулар ачыкланган очракта, Контроль-хисап палатасы күрсәтмәләре үтәлмәү, шулай ук Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларына контроль чаралар үткәрүгә комачаулау очрагында, Контроль-хисап палатасы җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль органнарга, тикшерелә торган оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына күрсәтмә җибәрә.

6. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәсендә конкрет хокук бозулар һәм күрсәтмә (предписание) чыгаруның конкрет нигезләре күрсәтелгән булырга тиеш.

7. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәсенә (предписаниесенә) Контроль-хисап органы рәисе имза куя.

8. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәсе (предписаниесе) анда билгеләнгән вакытлара үтәлергә тиеш.

9. Күрсәтмәнең (предписаниенең) үтәлү вакыты Контроль-хисап Палатасы карары буенча озайтылырга мөмкин, ләкин бер тапкырдан да артык түгел.

10. Контроль-хисап палатасы күрсәтмәсен (представлениесен) яисә күрсәтмәсен (предписаниесен) үтәмәү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка тартуг китерә.

11. Контроль чараларны үткәргәндә, җинаять яки коррупцион хокук бозу билгеләре күренгән муниципаль берәмлек бюджеты акчаларыннан законсыз файдалану фактлары ачыкланган очракта, Контроль-хисап палатасы кичекмәстән контроль чаралар материалларын хокук саклау органнарына тапшыра.

**18 статья. Тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның хокуклары гарантияләре**

1. Контроль чаралар уздырганда Контроль-хисап палатасы тарафыннан төзелгән актлар белешмә өчен тикшерелә торган органнар һәм оешмалар җитәкчеләренә җиткерелә. Тикшерелә торган органнар һәм оешмалар җитәкчеләренең Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән вакытка тапшырылган аңлатмалары һәм искәрмәләре актларга беркетеп бирелә һәм алга таба аларның аерылгысыз өлеше булып тора.

2. Тикшерелә торган органнар һәм оешмалар һәм аларның вазыйфаи затлары Контроль-хисап органының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белән вәкиллекле органга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

**19 статья. Контроль-хисап палатасының үзара хезмәттәшлеге**

1. Контроль-хисап палатасы үз эшчәнлеген тормышка ашырганда Россия Федерациясенең башка субъектлары һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, шулай ук Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Үзәк Банкының территориаль идарәләре, салым органнары, прокуратура органнары, башка хокук саклау, күзәтчелек һәм контроль органнары белән хезмәттәшлек итәргә хокуклы. Контроль-хисап палатасы алар белән хезмәттәшлек һәм үзара хезмәттәшлек турында килешүләр төзергә хокуклы.

2. Контроль-хисап палатасы Россия Федерациясе Контроль-хисап органнары берләшмәләренә (ассоциацияләренә), Россия Федерациясе субъектының контроль-хисап органнары берләшмәләренә (ассоциацияләренә) керергә хокуклы.

3. Контроль-хисап палатасы хезмәттәшлек һәм үзара хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләр нигезендә контроль һәм эксперт-аналитик чараларны үткәрүдә катнашуга контроль, хокук саклау һәм башка органнары һәм аларның вәкилләрен, шулай ук шартнамә нигезендә аудитор, фәнни-тикшерену, эксперт һәм башка учреждениеләрне һәм оешмаларны, аерым

белгечләрне, экспертларны, тәрҗемәчеләрне җәлеп итәргә хокуклы.

4. Контроль-хисап палатасы һәм башка дәүләт һәм муниципаль органнар үз эшчәнлеген җайга салу максатларында вакытлы, даими эшләүче уртак координация, консультация, киңәшләшү һәм башка эшче органнар оештыра ала.

5. Контроль-хисап палатасы Россия Федерациясенең башка субъектлары һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарының язмача мөрәҗәгате буенча алар үткәрә торган контроль һәм эксперт-аналитика чараларында катнаша ала.

6. Контроль-хисап палатасы Россия Федерациясе Хисап палатасына эшчәнлегенең тышкы муниципаль финанс контроле турында законнарга туры килүе турында бәяләмә һәм аның нәтиҗәлелеген арттыру буенча рекомендацияләр сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

**20 статья. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүматтан һәркем файдалана алырлык булуны тәэмин итү**

1. Контроль-хисап палатасы, үз эшчәнлеге турында мәгълүматтан һәркем файдала алырлык булуны тәэмин итү максатларында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында үткәрелгән контроль һәм эксперт-аналитик чаралар, аларны уздырганда ачыкланган хокук бозулар, кертелгән күрсәтмәләр (представлениеләр) һәм күрсәтмәләр (предписаниеләр), шулай ук алар буенча кабул ителгән карарлар һәм чаралар турында мәгълүмат урнаштыра.

2. Контроль-хисап палатасы ел саен муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына үз эшчәнлеге турында хисап бирә. Күрсәтелгән хисап Интернет челтәрендә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карап тикшергәннән соң гына урнаштырыла.

3. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм Интернет челтәрендә урнаштыру тәртибе Контроль-хисап палатасы Регламенты нигезендә башкарыла.

**21 статья. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеген финанс яктан тәэмин итү**

1. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү аңа йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган күләмдә карала.

2. Контроль-хисап палатасын карап тотуга акча муниципаль берәмлек бюджетында Россия Федерациясе бюджеты чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

3. Контроль-хисап палатасының бюджет акчаларын һәм муниципаль

мөлкәтне файдалануны контрольдә тоту муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының хокукый актлары нигезендә башкарыла.

**22 статья. Контроль-хисап палатасы хезмәткәрләренең матди, социаль тәэмин ителеше һәм гарантияләре**

1. Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларына акча бирү (акчалата бүләкләү), ел саен түләнә торган отпусклар (төп һәм өстәмә), һөнәри үсеш, шул исәптән өстәмә һөнәри белем алу, шулай ук муниципаль берәмлек муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар өчен билгеләнгән башка матди һәм социаль тәэмин итү чаралары (шул исәптән медицина һәм санатор-курорт тәэмин итү, көнкүреш, транспорт һәм башка хезмәт күрсәтү төрләре буенча) гарантияләнә.

Контроль-хисап палатасының вазыйфаи затларына еллык түләүле төп отпуск 30 календарь көн дәвамында билгеләнә.

2. Контроль-хисап палатасы рәисенә Балтач район Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының сайланулы вазыйфаи затларына акчалата бүләкләүләр билгеләү турында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы Контроль-хисап палатасы рәисенә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе» 28.04.2018 ел, №127 карары белән билгеләнгән күләмдә акчалата түләүләр, башка түләүләр билгеләнә.

3. Контроль-хисап палатасы рәисенә һәм инспекторларына җәмәгать судьяларын, хокук саклау һәм контрольдә тотучы органнарының вазыйфаи затларын дәүләт яклавы турында Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә, муниципаль берәмлек бюджеты хисабына тормыш һәм сәламәтлек өчен мәҗбүри дәүләт иминиятен дә кертеп, дәүләт яклавы гарантияләнә.

4. Муниципаль берәмлекнең Контроль-хисап органы рәисен, рәис урынбасарын, аудиторларны, инспекторларны һәм башка хезмәткәрләрне матди һәм социаль тәэмин итү чаралары федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

5. Контроль-хисап палатасы рәисе Контроль-хисап органында билгеләнгән гарантияләрне гамәлгә ашыру турында тиешле нигезләмәләрне раслый.

**23 статья. Йомгаклау нигезләмәсе**

Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр Балтач район Советының хокукый акты белән кертелә һәм билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.